ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 21 Бәйрәкәтамак ав. 11.11.2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, 2024 елның 12 июлендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 176-ФЗ санлы Федераль закон, 2014 елның 30 октябрендәге «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында»гы 82-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2024 елның 26 апрелендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 8 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 бүлегендәге 2 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 7 бүлек нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 10 бүлегенең икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент;»;

1.2. 2 бүлекнең 3 һәм 4 бүлекчәләрендә бүлекчә ахырында «.» тыныш билгесен «;» тыныш билгесе белән алмаштырырга»;

1.3. Карарның 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 5 бүлекчә өстәргә:

«5) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әгълиева